| МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

28.05.2019 № 214

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына биләнгәндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм ия булу, кулдагы акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалану тыелган, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының 01.07.2015 № 283 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлегенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы (алга таба – Татарстан Республикасы ГТХМ) структурасын һәм штат расписаниесен үзгәртүгә бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы ГТХМда дәүләт граждан хезмәте турындагы законнарны гамәлгә ашыру максатларында б о е р ы к б и р ә м :

1. Яңа теркәлгән редакциядә бәян итеп, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына биләнгәндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм ия булу, кулдагы акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларына (алда – Исемлек) ия булу һәм (яки) алардан файдалану тыелган, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы

эшләре һәм ГТХМның 01.07.2015 № 283 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлегенә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының дәүләт граждан хезмәткәрләренә кагыла торган өлешендә җиткерергә.

3. Биредәге Боерыкны үтәү контролен үземә калдырам.

Министр вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Н.В. Суржко

01.07.2015 № 283
Татарстан Республикасы
ГТХМ боерыгы белән
расланган (28.05.2019 №
214 боерык
редакциясендә)

**Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларына биләнгәндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм ия булу, кулдагы акча һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалану тыелган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеге**

Татарстан Республикасы Президентының 2006 ел 18 нчы гыйнвар № ПУ-9 «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Реестры турында» Указы белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры белән кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының югары төркеменә вазыйфалар:

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрының беренче урынбасары;

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры урынбасары.